Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

№ 15 (643) 16 август, 2017 ел (1438, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Чаллыда шәһәркүләм корбан чалу мәйданчыгы яңа сезонга әзерләнә



Чаллыда менә 7 нче ел корбан чалу Сидоровка бистәсендәге махсус җиһазландырылган мәйданчыкта башкарыла. Ул ел саен җентекләп әзерләнә, шәһәр службалары катнашында бу уңайдан мәйданчыкта киңәшмәләр уздырыла. Быелгы елда шундый беренче киңәшмә 1 августта булды. Анда Чаллы мөхтәсибәте, ветеринария, полиция вәкилләре, шәһәрне яшелләндерү, коммуналь предприятиеләр җитәкчеләре катнашты.

Киңәшмәне шәһәрнең Комсомол районы администрациясе башлыгы Александр Иванович Кислов үткәрде. Аның барышында һәр службаның корбан чалу мәйданчыгына бәйле конкрет бурычлары билгеләнде. Киңәшмәдә катнашучылар шулай ук мәйданчыкта Чаллы мөхтәсибәте җитәкчелегендә алып барылучы төзелеш эшләре белән таныштылар. Бүгенге көндә мәйданчыкны халык өчен даими мал чалу урыны итү буенча эш алып барыла. Биредә намаз бүлмәсе, ветеринар хезмәте өчен бүлмә, чалу, тунау урыны, суыткыч бүлмәсе төзелә. Мәйданчыкта киләчәктә эре маллар чалу да мөмкин булачак.

Киңәшмә ахырында А.И.Кислов болай диде: “Бүген безнең беренче киңәшмә узды, беренчел бурычларны билгеләдек. Корбан чалу йоласын халыкка уңайлы итеп үткәрү өчен барлык әзерлек эшләрен югары дәрәҗәдә башкара алырбыз дип уйлыйм. Чөнки шәһәр службаларының бу эштә инде шактый тәҗрибәсе бар.” Ә шәһәрнең баш ветеринар табибе Илдар Нургали улы Ногуманов болай диде: “Бүгенге киңәшмәдә мал табибләре, табиб экспертлар катнаша. Һәр елны безнең хезмәткәрләр тарафыннан мал мәйданчыкка тикшереп кенә кертелә, туналганнан соң түшкәләр дә ветеринария тикшерүе уза. Без инде биредә 7 ел эшлибез, үзем исә мәйданчыкта, Аллаһыга шөкер, 5 ел катнашам.”

**Рәсемнәрдә:** киңәшмәдән күренешләр; мал чалу мәйданчыгы; мал чалу цехы; булачак намаз бүлмәсе.



## Балалар көндезге лагерьда Коръән ятлый

Чаллының “Тәүбә” мәчетендә Коръән ятлаучы балалар өчен айлык лагерь эшләде. Аңа 7 яшьтән 15 яшькә кадәрге 16 ир бала җәлеп ителде. Мәчет имам-хатыйбы Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев болай ди: “Иң яхшы укучыларны җыю һәм ай буена җүз ярым Коръән ятлату бурычын куйган идек. Кемдер бу максатка иреште, кемдер ирешә алмады. Кайсыберләре бер җүз, икенчеләр ярты җүз ятладылар. Гомумән алганда, бик уңышлы булды. Коръән ятлау дәресләреннән тыш, балалар футбол уйнадылар, Камада көймәдә йөзделәр, су коендылар, экскурсияләргә чыктылар, тәмле ашлар ашадылар. Балалар бик канәгать, әлхәмделилләһ.”

Коръән ятлаучылар лагере 10 августка кадәр дәвам итте. Бу смена тәмамлангач мәчеттә 14 августта мөселман балалары өчен чираттагы лагерь ачыла. Ул быелгы җәйге сезонда сан ягыннан караганда өченчесе булачак һәм атна дәвамында эшләячәк.

Мәчеттә балаларның беренче көндезге лагере 10-19 июльдә эшләгән иде. Анда 50 бала ял итте.



**Рәсемдә:** **“Тәүбә” мәчете лагерында Коръән ятлаучы балалардан бер төркем.**



## Хаҗ дәресләре уңышлы узды

Чаллы мөхтәсибәте каршында һәр елны хаҗга әзерлек дәресләре уздырыла. Быел аны 40 кеше тәмамлады. Дәресләр Сидоровка бистәсендәге “Ихлас” мәчетендә якшәмбе көннәрендә алып барылды. Ә 6 августта аларның соңгысы — йомгаклау дәресе булды. Биредә хаҗга җыенучылар алган белемнәре буенча язма рәвештә имтихан тапшырдылар. Курсларны уңышлы үтүчеләргә шаһәдәтнамәләр тапшырылды.

Хаҗ буенча дәресләрне мөхтәсибәтнең хаҗ буенча җаваплы хезмәткәре Илназ хәзрәт Яхин үткәрде. Ул үзе укыткан хаҗиләр төркемен олуг хаҗда да җитәкләячәк.

**Рәсемдә:** йомгаклау дәресе бара.

# Рамазаннан соң җиңелү

Ий Аллаһка иман китергән бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз хакыйкый курку белән. Аллаһка тәкъва булыгыз. Тәкъвалык ул бөтен кешеләргә кагыла торган Аллаһның васыяте һәм әмере, Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтте: **“Дөреслектә без сезгә һәм сезгә хәтле булган китап әһелләренә - Аллаһка карата тәкъва булыгыз, дигән васыятьне әмер иттек”** (Ниса, 131).

Менә рамазан ае да үзенең бәрәкәтле вакыты, күп гыйбадәтләре, тәүбә һәм Аллаһка ялварулары белән үтеп китте. Аллаһтан сорыйбыз гыйбадәтләребезнең кабул булуын.

Рамазан ае үтеп китте һәм аның урынына рамазаннан тыш вакыт җитте. Шушы вакытта һәрберебез үзебезнең хәлебезгә карарга тиеш. Әгәр дә кемдәдер рамазан аеннан соң гыйбадәтләргә карата сүлпәнлек һәм гафиллек күренә башласа, ул бер хакыйкатьне аңласын: бу бөтенесе дә аның дошманнары сәбәпле барлыкка килде. Сак булыйк сүлпәнлек һәм гафиллек дигән афәтләрдән!

Имам Әхмәд һәм башка имамнар, Габдулла ибн Гамр риваятендә килгән хәдисне тапшыралар, шушы хадистә сөекле пәйгамбәребез әйтә: “Һәр гыйбадәт башында дәрт һәм гайрәтлек булыр.” менә рамазан аенда нәкъ шулай булды. Бик күбебез дәртләнеп зур гыйбадәтләргә иреште. Шуннан соң сөекле пәйгамбәребез давам итеп әйтә: “Ә һәр дәрт һәм гайрәтлек артыннан сүлпәнлек килер.”

Әйе, күбебезнең хәле нәкъ сөекле пәйгамбәребез әйтүенчә, зур гыйбадәтләрдән соң килгән сүлпәнлек - ул күп мөселманнарның чире. Шуңа күрә кем шушы чирдән сакланмаса, бу чир аны басачак, шуннан соң аның дошманнары шунда ук килеп җитеп, шушы кешене бөтенләй юкка чыгарырга тырышырлар.

Ий Аллаһның колы, син үзеңнең дошманнарыңны беләсеңме!? Беләсеңме, кем синең сүлпән һәм гафил булган вакытта, яныңа килеп җитә һәм туры юлдан яздырырга тырыша!?

Ий Аллаһның колы, синең дошманнарың: нәфесең, теләкләрең һәм шайтаннар! Алар рамазан аеннан соң синнән үч алырга телиләр. Әгәр дә син аларга каршы көрәшкә чыкмасаң, аларның корбанына әйләнерсең! Шуңа күрә кемнең Аллаһка гыйбадәт итүдә давамлы буласы килсә, вәҗиб булып тора сүлпәнлеккә һәм гафилеккә бирешмәскә. Һәм рамазаннан тыш вакытларда да зур теләк белән гыйбадәтләрне башкарырга.

Сак булыгыз сүлпән һәм гафил булудан!

Безнең нәфесебез даими рәвештә яман эшләрне эшләргә куша! Әгәр дә ул безнең сүлпән һәм гафил булуыбызны сизсә, тизрәк үзенең яман теләкләрен әмер итә башлый. Аллаһ Тәгалә Коръәндә безгә аның вәсвәсә кылуы, яман әйберләрне матур итеп күрсәтүе, гөнаһка, тәртипсезлеккә, түбәнчелеккә чакыруы турында хәбәр итте: “Дөреслектә Без Адәм баласын юктан бар иттек һәм без беләбез аның нәфесе ниләр вәсвәсә итүен.”

Син уйлыйсың рамазан аенда нәфесеңне кулда тота алдың, ә ул синең тынычлануыңны, хәл алуыңны гына көтеп тора, шуннан соң яңадан туры юлдан, гыйбадәтләрдән яздыра башлый.

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: “Аның нәфесе үзенең бер туган абыйсын үтерүен матур итеп күрсәтте һәм аңа этәрде.”

Күрдегезме нәфеснең яман эшен!? Кадерле дин кардәшем, бел: син бер кайчан да диндә, гыйбадәттә нык тора алмассың, иллә мәгәр нәфесеңә киртә куйганчыга тикле!

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: **“Җан белән һәм җанны юктан бар иткән Аллаһ белән ант итәм. Аллаһ Тәгалә җаннарны юктан бар итте, шуннан соң шушы җаннарга явызлык һәм изгелек юлларын күрсәтте”** (Шамс, 6, 7).

Ибн Кудама ал-Макдаси үзенең “Мухтасару минхаҗи касыдин” дигән хезмәтендә яза: “Бел синең нәфесең һәм яман теләгең — иң явыз дошманың. Сак бул нәфесеңә буйсынырга!”

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: “Дөреслектә нәфес ул даими рәвештә яманлыкны әмер итә.”

Бу бөтенесе дә нәфеснең хәле!

Икенче дошманың шулай ук синең эчеңдә, әгәр дә ул синең сүлпән һәм гафил булуыңны сизсә шунда ук үзенә буйсындырырга тырыша! Аның исеме һава, ягъни яман теләкләр.

Хакыйкатьтә яман теләкләр күп кешеләрнең иләһе! Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: “Күрдеңме син шундыйларны, кем яман теләкләрен үзенә иләһ итеп алды?”

Аллаһ Тәгалә бөек хикмәт өчен бездә шушы яман теләкләр булуын яратты, ләкин Аллаһ Тәгалә безне яман теләкләргә каршы килергә әмер итте! Шуңа күрә сак бул яман теләкләрең артыннан иярүдән! Аллаһ Тәгалә әйтә: **“Кешеләр арасында күбрәк адашучы шул, кем үзенең яман теләкләре артыннан ияреп барса.”**

Бишр ал-Хафи әйтте: “Бу дөньяда бөтен бәлә-каза яман теләкләр артыннан ияру сәбәпле барлыкка килә, шуңа күрә бәла-казалардан имин буласың килсә яман теләкләр артыннан иярә күрмә.”

Ибн Джаузи әйтте: “Яман теләкләр кешене төрле гөнаһлар каршына алып киләләр һәм алар гакыллы кешене гакылсыз, мәҗнүн дәрәҗәсенә төшерәләр.”

Сак булыгыз үзегезнең яман теләкләрегез артыннан иярүдән!

Әгәр дә синең теләкләр хакка каршы килсәләр һәм син хакны читтә калдырып яман теләкләргә буйсынсаң, бел, син үзеңнең теләкләреңә гыйбадәт кылдың, таныйсыңмы син аны яисә инкарь итәсең. Вә ләкин әгәр дә син яман теләкләр өчен хакны калдырмасаң, Аллаһка хәмед-сәнәләреңне әйт, чөнки син Аллаһка гына гыйбадәт итәсең һәм үзеңнең теләкләреңне җиңә аласың.

Өченче дошманыбыз — иблис һәм аның гаскәре. Бу дошманыбыз иң куркыныч. Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә иблис турында әйтә: “Ул, ягъни иблис һәм аның гаскәре сезне күзәтеп тора, ә сез аларны күрмисез.”

Аллаһ Тәгалә иблисне безгә каршы гөнаһларыбыз өчен җибәрә. Иблис калебләребезгә хәтле керә, шунда ул нәфес һәм теләкләр белән бергәләшеп, безне һәлак итәргә тырыша.

Шулай итеп безгә каршы өч дошман бәрләшә һәм алар бездән үч алырга тырышалар. Әгәр дә кеше кыска вакытта Аллаһка гыйбадәттә булса, шуннан соң аңа сүлпәнлек, гафиллек һәм иман зәгыйфьлеге килсә, ул белсен: бу өч дошман шунда ук килеп җитәр һәм аны һәлак итәргә тырышырлар!

Имам Әхмәд, Сабура риваятендә килгән хәдисне тапшыра. Шушы хәдистә сөекле пәйгамбәребез әйтә: “Шайтан кеше өчен хәерлеккә илтә торган юлларда утыра һәм әгәр дә кеше ислам динен кабул итергә теләсә, ул аңа әйтә: “Ислам динен кабул итеп син үзеңнең моңа кадәр тоткан динеңне калдырасың мени?” Әгәр дә берәр кем һиҗрәт кылырга теләсә, ул аңа әйтә: “Син туган җиреңне калдырасың мени?”

Шайтан безне саклап кына тора. Әгәр дә син Аллаһка буйсынырга теләсәң, ул шунда ук килеп җитә һәм тыя башлый.

Сак булыгыз гыйбадәттә ялкау, гафил һәм сүлпән булудан!

Әгәр дә син гыйбадәт кылуда авырлык күрсәң бел: бу бөтенесе дә шушы өч дошманның эше, бу иман куәтеннән түгел! Бу синең ихлас булуыңнан түгел! Юк, бу - дошманнарыңның сине җиңүе.

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә шайтан турында әйтә: “Иблис әйтте: Мин аларның туры юлында утырырмын, ягъни изге эшләрне кылырга комачауларммын.”

Бу дөньяда нинди генә хәерле юл булмасын, иблис шушы юлда утырачак һәм сине шушы юлдан биздерергә тырышачак. Һәм нинди генә бозыклы юл булмасын, иблис шушы юлга чакырачак.

Шушы дошманнардан котылу юллары күп. Без барыбыз да аларны белергә мохтаҗ. Аллаһ сине юктан бар итте һәм ул сине ялгыз калдырмады, Ул сиңа Үз ярдәмен биреп тора! Аллаһ Тәгалә синдә калебне нәфескә каршы, ә сәламәт гакылны яман теләкләргә каршы кулланырга бирде, фәрештәләрне шайтаннарга каршы җибәрде. Ләкин калебең, гакылың һәм фәрештәләр сиңа ярдәм итәчәкләр, син аларга ярдәм иткән чаклы микъдарда. Шуңа күрә әгәр дә кеше үзенең гакылына каршы килсә, калебен ишетмәсә, фәрештәләрнең чакыруын читтә калдырса, алар аны үзләренең ярдәменнән калдырачаклар!

Сак бул сәламәт калеб чакырган нәрсәне калдырудан!

Сак бул киләчәктә буласы нәтиҗәне аңлаган гакылны тыңламаудан!

Габдурразак ас-Сангани һәм ат-Табари язган тафсир китапларында, ибн Мәсгуд дигән сәхәбәдән хәдис китерелә ( ул хәдис хәсән дәрәҗәсендә, аның хөкеме “ар-рафг). Ул әйтте: **“Дөреслектә фәрештә кешегә яхшы гамәлләрне эшләргә илһам бирә, ә шайтан яман эшләргә котырта.”**

Шулай итеп, һәрберебезнең йөрәгендә көрәш бара: бер яктан фәрештә изгелеккә чакыра, икенче яктан шайтан начарлыка котырта. Һәм җиңү тәкъвалы кешеләргә булачак.

Шуңа күрә әгәр дә берәр кем рамазаннан тыш вакытта, рамазан аенда сыман буласы килсә, шушы дошманнарга каршы көрәш алып барсын. Әгәр дә берәр кем бер вакыт Аллаһка гыйбадәттә булса, ә шуннан соң гыйбадәттән өзелсә, Аллаһ Тәгаләдән өзелгән булыр. Аллаһ Тәгалә безне барыбызны да Аннан өзелүдән сакласын иде.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы .**

# Шайтан суы

Аракыны һәм башка төрле исерткеч эчемлекләрне халык телендә "шайтан суы", "яшел елан" дип тә атыйлар. Ә казахлар аңа "котырткыч" диләр. Халык телендә башка исемнәре дә бар.

Ничек кенә аталса да, алар барсы да кешене исертергә, акылын җуярга, туры юлдан адаштырырга юнәлтелгән.

Мөселман дөньясында исерткеч эчемлекләренең барлыкка килүе турында төрле риваятьләр бар. Шуларның берсенә тукталып искә алаек.

Иблис мәлгун оҗмахтан куылып җиргә сөрелгәч, җир йөзендәге кешеләрне туры юлдан адаштырырга Аллаһы Тәгаләдән рөхсәт сорый: "Син мине адәм аркасында җиргә сөрдең, рөхсәт бир миңа кешеләрне Синең юлыңнан адаштырырга, Сиңа буйсынмаска, Синең боерыкларыңны үтәмәскә,"- дип. Аллаһы Тәгалә әйтте: "Теләгеңне кабул итәм. Адәм балаларының әҗеленнән башкасын. Миңа чын күңелләре белән ихлас ышанганнары (иманнары ныклы булганнары), Коръән буенча гына гамәл кылганнары, Минем боерыгымны үтәгәннәре синең арттан иярмәсләр."

Иблис бик шатланып Аллаһы Тәгаләнең рөхсәтен кабул итә. Үзенең күп санлы шайтаннары янына кайтып бу шатлыклы хәбәрне аларга җиткерә. Иблис шайтаннарны алты төркемгә бүлә. Һәм һәр төркемгә бер вазыйфа үтәргә боера. Бер төркеменә исерткеч эчемлекләр — хәмер эшләргә боерык бирә. Һәм аларны дөньядагы исерткеч эчемлекләренең хуҗалары итеп билгели. Икенче төркем шайтаннарга музыка кораллы эшләргә боера һәм аларны дөньядагы барча музыка коралларының хуҗалары итә.

Шайтаннар алар бик осталар, Иблис нәрсә боера - шуларны тиз генә башкаралар, тормышка ашыралар.

Менә исерткеч эчемлекләр әзер. Ә ничек соң кешеләрне эчертеп исертергә? Музыка кораллары да әзер. Иблис шайтаннары кешеләр яшәгән урынга якынырак килеп, сафка тезелеп каты тавыш белән музыка уйный башлый. Бер вакытта да матур музыка тавышларын ишетмәгән кешеләр музыка чыккан якка йөгерәләр. Иблис һәрберсен куанып каршы ала. Килгән кешеләргә зур хөрмәт күрсәтеп, аларны исерткеч эчемлекләр белән сыйлый. Музыкасы да күңелле итеп уйнап тора.

Мондый мәҗлесне тәүге тапкыр күргән кешеләргә ул бик ошый. Мәҗлескә килгән кешеләргә Иблис исерткеч эчемлекләрне әзерләү серләрен һәм уен кораллары эшләү тәртибен өйрәтә.

Шулай итеп адәм балаларының кайберләре шайтан колына әйләнә. Алар Иблис һөнәренә өйрәнеп башка кешеләрне дә бу һөнәргә өйрәтә башлыйлар.

Менә шулай бу һөнәрләр камилләшеп безнең заманга хәтле килеп җитте. Исерткеч эчемлекләрнең, музыка коралларының ниндиләре генә юк хәзер.

Шушы риваятькә таянып исерткечне "шайтан суы" дип атаулары дөрестер.

Исерткеч эчүчеләрнең күңелләренә шайтаннар хәмер эчүне күркәм гамәл итеп күрсәтәләр. Шуның өчен хәмер эчәргә яраткан кешеләр аракыдан аерыла алмыйлар, эчеп тә туймыйлар. Чөнки шайтан кешенең күңелен котыртып тора, һәрчак хәмер эчәргә өнди. Кешеләрне эчертеп туры юлдан яздыруына Иблис шатлана гына.

Эчкечелектән котылу өчен ныклы, ышанычлы бер генә юл бар. Ул — Ислам дине. Кем Аллаһының җебенә, Коръәнгә ныклап тотына — ул кеше Иблис юлына баса алмый.

Хөкүмәт кешеләре эчкечелеккә каршы нинди генә тозак корып карамыйлар - нәтиҗәсе юк. Һәм булмаячак та. Төрле тискәре күренешләрне, төрле җинаятьчелекне Ислам дине генә бетерә ала. Илдәге эчкечелекне киметүгә, юкка чыгарыруга юнәлтелгән төрле карарлар чыгаралар, каты тәртипләр куялар. Мәсәлән, кибетләрдә аракы сатуны сәгатьләр, яшь белән чикләп карадылар, бәяләрен күтәрделәр, эчкечелекнең кеше өчен зарары турында күп язалар, сөйлиләр. Ләкин эчкечелекне киметергә, юкка чыгарырга нәтиҗәле һич бер юл таба алмыйлар. Чөнки хөкүмәт җитәкчеләре диннән читтә юл эзлиләр, Аллаһыдан ярдәм сорамыйлар.

**Исмәгыйль хәзрәт Хәким**
**Башкортостанның Учалы шәһәре.**

---

*Укучыларыбыз иҗаты*

## Үкенечле генә булмасын

Дөнья үзе безне сайлаган шул
Без дөньяны сайлап килмәдек;
Туган чакта кемнән туасын да,
Кая туасын да белмәдек.
Гомер бик тә озын кебек иде
Ә ул мизгел генә икән бит;
Тәмен тоярга да өлгермибез
Китәргә дә вакыт җитә бит.
Җаннар җиргә килеп кенә китә
Татыр өчен дөнья нужасын;
Авырлыгына да түзәрбез без
Үкенечле генә булмасын.
Киләчәкне үзебез ясыйбыз -
Онытмасак иде шуларны;
Сөю белән гафу итә белү
Коткарып калачак җаннарны.

## Ярдәм итә миңа мәхәббәт

Күңелем шат, йөзем якты минем,
Яшәве дә миңа бик рәхәт;
Бәхетле булырга ярдәм итә
Илаһыма булган мәхәббәт.
Бар галәмне юктан бар кылган Ул
Безне сөеп, безне яратып;
Илаһымның чиксез мәхәббәтен
Сүзләр белән булмый аңлатып.
Илаһымның чиксез мәхәббәте
Минем көчем, минем терәгем;
Илаһыма зекер, рәхмәт әйтеп
Тибә һәрчак минем йөрәгем.

## Дөнья малы

Дөньядагы тормыш кыска мизгел -
Килмәгән без монда мәңгегә;
Дөнья малыннан җан рәхәт тапмый
Рәхәт таба бары тән генә.
Дөнья малы - дуңгыз каны бит ул,
Табынмагыз дөнья малына!
Шөкер итеп яши белгән кеше
Тынычлык табачак җанына.
Коръәнендә Аллаһ әмер иткән
Җаныбызны чиста сакларга;
Ник соң безгә Олы җаныбызны
Дөнья малы өчен вакларга?
Әле безнең Күк капкасын ачып
Җәннәтләргә керер көннәр бар;
Тик дөньяга мөкиббән киткәннәр
Ул капканы ача алмаслар.
Һәр кешегә Раббым насыйп итсен
Хәләл эшне, хәләл малларны;
Ә хәрам мал йортыбызга кереп
Тапламасын безнең җаннарны.

## Үзе ярдәмен бирер

Коръән сүзләрен ишетсәм
Җан тынычлыгы табам;
Аллаһымның барлыгына,
Берлегенә ышанам.
Урамда төн булганда да
Күңелемдә якты көн;
Өем бик зур булмаса да
Минем күңелем иркен.
Бар туганнар, бар якыннар
Сыя минем йөрәккә;
Алар да миңа булыша
Миңа ярдәм кирәктә.
Яшим әле, рәхәт яшим
Аллаһыма мең шөкер;
Киләчәктә дә Илаһым
Үзе ярдәмен бирер.

## Аллаһ Рәхмәтенә ирешербез

Мин үземне бик бәхетле тоям,
Раббым бирде миңа барын да;
Киң күңелле туганнарны бирде,
Кимсетмәде дошман каршында.
Шигырьләрем ярдәм итә алса
Кешеләргә авыр чакларда,
Күңелләренә сабырлык биреп
Җан тынычлыкларын сакларга.
Миннән дә бәхетле кеше булмас,
Әгәр чынга ашса теләгем;
Мин бит җир йөзендә туып-үскән
Һәр кешегә бәхет теләдем.
Килеп кенә китүче тормышның
Кадерләрен белеп яшик без;
Биргән сынауларга сабыр булсак
Аллаһ Рәхмәтенә ирешербез.

## Әйдәгез, бергәләп тырышыйк!

Яз кояшы җанымны җылыта,
Яшәр өчен миңа көч бирә;
Күңелемә якты өмет салып
Җитмеш беренче кат яз килә.
Миңа мәгълүм түгел гомеремдә
Тагын ничә язның киләсе;
Әмма җирдә тынычлык булуын
Бик күрәсе килә, күрәсе.
Дога кылам һәркөн Илаһыма
Урнаштыр, дип, җирдә тынычлык;
Әйдәгез, бергәләп дога кылыйк,
Әйдәгез, бергәләп тырышыйк!

## Саклый белүче сирәк

Кеше рәхәткә чыдамый,
Ә авырлыкларга түзә;
Балык та бит һәрвакытта
Агымга каршы йөзә.
Авырлыктан качкан саен
Зуррак авырлык килә;
Ә каршы тора башласак
Раббым ярдәмен бирә.
Ак белән карадан гына
Тормый гомернең юлы;
Ул бит бик күп төсләргә бай
Һәм бәхет белән тулы.

* * *

Чын бәхетне табу өчен
Бик күп тырышлык кирәк;
Әмма тапкан чын бәхетне
Саклый белүче сирәк.

## Тәнкыйть сүзләре

Әче әрем чүп үләне генә
Бик матур да түгел, әче дә;
Әмма дару итеп кулланганда
Шифа бирә бик күп кешегә.
Тәнкыйть сүзләре дә әрем кебек
Чыттырса да безнең йөзләрне;
Икейөзле ялагай сүзеннән
Файдалырак алар үзләре.

**Динә Ясәвиева - Гатиятуллина**
**Яшел Үзән шәһәре.**

# Намаз вакытлары

| Милади Сентябрь | Көн исеме | Зөлхиҗҗә, Мөхәррам | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Чаллы | Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Чаллы | Казан | Кояш чыга Уфа | Чаллы | Казан | Зәвәл Уфа | Чаллы | Казан | Өйлә Уфа | Чаллы | Казан | Икенде Уфа | Чаллы | Казан | Ахшам Уфа | Чаллы | Казан | Ястү Уфа | Чаллы | Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Жм | 10 | 04.00 | 02.07 | 02.20 | 04.51 | 03.03 | 03.16 | 06.21 | 04.33 | 04.46 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.56 | 16.11 | 16.24 | 20.09 | 18.25 | 18.38 | 22.00 | 20.20 | 20.33 |
| 2 | Шм | 11 | 04.03 | 02.11 | 02.23 | 04.53 | 03.05 | 03.18 | 06.23 | 04.35 | 04.48 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.54 | 16.09 | 16.22 | 20.06 | 18.23 | 18.36 | 21.57 | 20.17 | 20.30 |
| 3 | Як | 12 | 04.06 | 02.14 | 02.27 | 04.54 | 03.07 | 03.20 | 06.24 | 04.37 | 04.50 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.52 | 16.07 | 16.20 | 20.04 | 18.20 | 18.33 | 21.54 | 20.13 | 20.27 |
| 4 | Дш | 13 | 04.09 | 02.17 | 02.30 | 04.56 | 03.09 | 03.22 | 06.26 | 04.39 | 04.52 | 13.14 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.50 | 16.05 | 16.18 | 20.01 | 18.18 | 18.31 | 21.50 | 20.10 | 20.23 |
| 5 | Сш | 14 | 04.12 | 02.20 | 02.33 | 04.58 | 03.11 | 03.24 | 06.28 | 04.41 | 04.54 | 13.14 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.48 | 16.03 | 16.16 | 19.59 | 18.15 | 18.28 | 21.47 | 20.07 | 20.20 |
| 6 | Чш | 15 | 04.14 | 02.23 | 02.36 | 05.00 | 03.13 | 03.26 | 06.30 | 04.43 | 04.56 | 13.14 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.46 | 16.01 | 16.14 | 19.56 | 18.12 | 18.26 | 21.44 | 20.03 | 20.17 |
| 7 | Пж | 16 | 04.17 | 02.26 | 02.39 | 05.02 | 03.15 | 03.28 | 06.32 | 04.45 | 04.58 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.45 | 15.59 | 16.12 | 19.54 | 18.10 | 18.23 | 21.41 | 20.00 | 20.13 |
| 8 | Жм | 17 | 04.20 | 02.29 | 02.42 | 05.04 | 03.17 | 03.30 | 06.34 | 04.47 | 05.00 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.42 | 15.57 | 16.10 | 19.51 | 18.07 | 18.20 | 21.38 | 19.57 | 20.10 |
| 9 | Шм | 18 | 04.23 | 02.32 | 02.45 | 05.05 | 03.19 | 03.32 | 06.35 | 04.49 | 05.02 | 13.13 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.40 | 15.55 | 16.08 | 19.49 | 18.05 | 18.18 | 21.35 | 19.54 | 20.07 |
| 10 | Як | 19 | 04.25 | 02.35 | 02.48 | 05.07 | 03.21 | 03.34 | 06.37 | 04.51 | 05.04 | 13.12 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.38 | 15.53 | 16.06 | 19.46 | 18.02 | 18.15 | 21.32 | 19.51 | 20.04 |
| 11 | Дш | 20 | 04.28 | 02.38 | 02.50 | 05.09 | 03.23 | 03.36 | 06.39 | 04.53 | 05.06 | 13.12 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.36 | 15.51 | 16.04 | 19.44 | 17.59 | 18.13 | 21.29 | 19.47 | 20.01 |
| 12 | Сш | 21 | 04.31 | 02.40 | 02.53 | 05.11 | 03.25 | 03.38 | 06.41 | 04.55 | 05.08 | 13.12 | 11.26 | 11.39 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.34 | 15.48 | 16.01 | 19.41 | 17.57 | 18.10 | 21.26 | 19.44 | 19.57 |
| 13 | Чш | 22 | 04.33 | 02.43 | 02.56 | 05.13 | 03.27 | 03.40 | 06.43 | 04.57 | 05.10 | 13.11 | 11.26 | 11.39 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.32 | 15.46 | 15.59 | 19.39 | 17.54 | 18.07 | 21.23 | 19.41 | 19.54 |
| 14 | Пж | 23 | 04.36 | 02.46 | 02.59 | 05.15 | 03.29 | 03.42 | 06.45 | 04.59 | 05.12 | 13.11 | 11.26 | 11.39 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.30 | 15.44 | 15.57 | 19.36 | 17.52 | 18.05 | 21.20 | 19.38 | 19.51 |
| 15 | Жм | 24 | 04.38 | 02.48 | 03.01 | 05.17 | 03.30 | 03.44 | 06.47 | 05.00 | 05.14 | 13.11 | 11.25 | 11.38 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.28 | 15.42 | 15.55 | 19.34 | 17.49 | 18.02 | 21.17 | 19.35 | 19.48 |
| 16 | Шм | 25 | 04.41 | 02.51 | 03.04 | 05.18 | 03.32 | 03.45 | 06.48 | 05.02 | 05.15 | 13.10 | 11.25 | 11.38 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.26 | 15.40 | 15.53 | 19.31 | 17.46 | 17.59 | 21.14 | 19.32 | 19.45 |
| 17 | Як | 26 | 04.43 | 02.54 | 03.07 | 05.20 | 03.34 | 03.47 | 06.50 | 05.04 | 05.17 | 13.10 | 11.25 | 11.38 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.24 | 15.38 | 15.51 | 19.28 | 17.44 | 17.57 | 21.11 | 19.29 | 19.42 |
| 18 | Дш | 27 | 04.46 | 02.56 | 03.09 | 05.22 | 03.36 | 03.49 | 06.52 | 05.06 | 05.19 | 13.10 | 11.25 | 11.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.22 | 15.35 | 15.48 | 19.26 | 17.41 | 17.54 | 21.08 | 19.26 | 19.39 |
| 19 | Сш | 28 | 04.48 | 02.59 | 03.12 | 05.24 | 03.38 | 03.51 | 06.54 | 05.08 | 05.21 | 13.09 | 11.24 | 11.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.20 | 15.33 | 15.46 | 19.23 | 17.38 | 17.52 | 21.05 | 19.23 | 19.36 |
| 20 | Чш | 29 | 04.50 | 03.01 | 03.14 | 05.26 | 03.40 | 03.53 | 06.56 | 05.10 | 05.23 | 13.09 | 11.24 | 11.37 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.17 | 15.31 | 15.44 | 19.21 | 17.36 | 17.49 | 21.02 | 19.20 | 19.33 |
| 21 | Пж | 1 | 04.53 | 03.04 | 03.17 | 05.28 | 03.42 | 03.55 | 06.58 | 05.12 | 05.25 | 13.09 | 11.23 | 11.36 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.15 | 15.29 | 15.42 | 19.18 | 17.33 | 17.46 | 20.59 | 19.17 | 19.30 |
| 22 | Жм | 2 | 04.55 | 03.06 | 03.19 | 05.29 | 03.44 | 03.57 | 06.59 | 05.14 | 05.27 | 13.08 | 11.23 | 11.36 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.13 | 15.27 | 15.40 | 19.16 | 17.30 | 17.44 | 20.56 | 19.14 | 19.27 |
| 23 | Шм | 3 | 04.57 | 03.08 | 03.21 | 05.31 | 03.46 | 03.59 | 07.01 | 05.16 | 05.29 | 13.08 | 11.23 | 11.36 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.11 | 15.24 | 15.37 | 19.13 | 17.28 | 17.41 | 20.54 | 19.11 | 19.24 |
| 24 | Як | 4 | 05.00 | 03.11 | 03.24 | 05.33 | 03.48 | 04.01 | 07.03 | 05.18 | 05.31 | 13.08 | 11.22 | 11.35 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.09 | 15.22 | 15.35 | 19.11 | 17.25 | 17.38 | 20.51 | 19.08 | 19.21 |
| 25 | Дш | 5 | 05.02 | 03.13 | 03.26 | 05.35 | 03.50 | 04.03 | 07.05 | 05.20 | 05.33 | 13.07 | 11.22 | 11.35 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.07 | 15.20 | 15.33 | 19.08 | 17.23 | 17.36 | 20.48 | 19.05 | 19.18 |
| 26 | Сш | 6 | 05.04 | 03.16 | 03.29 | 05.37 | 03.52 | 04.05 | 07.07 | 05.22 | 05.35 | 13.07 | 11.22 | 11.34 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.04 | 15.18 | 15.31 | 19.05 | 17.20 | 17.33 | 20.45 | 19.02 | 19.15 |
| 27 | Чш | 7 | 05.06 | 03.18 | 03.31 | 05.39 | 03.54 | 04.07 | 07.09 | 05.24 | 05.37 | 13.07 | 11.21 | 11.34 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.02 | 15.15 | 15.28 | 19.03 | 17.17 | 17.30 | 20.43 | 18.59 | 19.13 |
| 28 | Пж | 8 | 05.08 | 03.20 | 03.33 | 05.41 | 03.56 | 04.09 | 07.11 | 05.26 | 05.39 | 13.06 | 11.21 | 11.34 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.00 | 15.13 | 15.26 | 19.00 | 17.15 | 17.28 | 20.40 | 18.57 | 19.10 |
| 29 | Жм | 9 | 05.11 | 03.22 | 03.35 | 05.43 | 03.58 | 04.11 | 07.13 | 05.28 | 05.41 | 13.06 | 11.20 | 11.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.58 | 15.11 | 15.24 | 18.58 | 17.12 | 17.25 | 20.37 | 18.54 | 19.07 |
| 30 | Шм | 10 | 05.13 | 03.25 | 03.38 | 05.44 | 03.59 | 04.13 | 07.14 | 05.29 | 05.43 | 13.05 | 11.20 | 11.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.56 | 15.09 | 15.22 | 18.55 | 17.09 | 17.23 | 20.34 | 18.51 | 19.04 |

## Лагерьлар дәвам итә

Чаллы мәчетләре каршында балаларның көндезге лагерьлары дәвам итә. Аларның чираттагысы 31 июл — 6 август чорында "Нур-Ихлас" мәчетендә эшләде. Биредә 8 -13 яшьлек 35 ир бала ял итте. Көндезге лагерь программасы күп төрле чараларны үз эченә алды: дин-әхлак дәресләре, стена газеталары чыгару, батут үзәгенә бару, экскурсияләр. Мәчет газонында балалар өчен махсус футбол кыры да корылган иде. Лагерь белән "Кол Шәриф оныклары" хәрәкәтендә күп еллар актив катнашкан, шушы хәрәкәттә дини-милли тәрбия алган егетләр җитәкчелек итте, алар тәҗрибәләрен хәзер үзләреннән кечерәкләргә тапшырып калдырырга теләделәр.



**Рәсемнәрдә:** балалар көндезге ашта.

## Танышырга телим

Миңа 74 яшь, буем 166 см., авырлыгым 70 кг. Самара өлкәсендә район үзәгендә ике бүлмәле фатирда берүзем яшим. Холкым яхшы. Акыллы, яхшы холыклы, курчак "Барби" кебек, шаяруны аңлый торган, тәмле ашлар пешерә торган, минем янга күчеп килә торган ялгыз ханым белән гаилә корырга телим. Тел. 89397578172

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен: e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча 16 август 16 сәг.**
**фактта 16 август 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**